Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

От 2021 ел 14 нче декабрь № 23

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Камай авыл җирлегендә Яңа ел
бәйрәмнәренә әзерлек һәм үткәрү
чорында янгын куркынычсызлыгын
тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2021 елның 8 декабрендәге 1194 номерлы карары нигезендә һәм Камай авыл җирлегендә Яңа ел бәйрәмнәренә әзерлек һәм үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. 2021 нче елның 20 нче декабреннән 2022 нче елның 9 нчы гыйнварына кадәр Камай авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырыга.

2. Яңа ел бәйрәмнәренә әзерлек һәм үткәрү чорында мәдәният һәм мәгариф, сәламәтлек саклау һәм сәүдә учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Яңа ел бәйрәм чараларына әзерлек һәм аларны уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга (беренчел янгын сүндерү чаралары, эвакуация чыгу юллары, автоматик янгын сигнализациясе, электр үткәргечләр (сүндергечләр, розеткалар) һәм башкалар.)
- биналарны бизәгәндә бары тик сертификацияләнгән электр гирляндалары, иллюминацияләр һәм башка бәйрәм атрибутларын гына кулланырга ;
- кышкы чорда юлларны, объектларга керү юлларын вакытында кардан һәм боздан чистартуны оештырырга;
- Яңа ел чараларын үткәрү урыннарында янгынга каршы нормаларның һәм кагыйдәләрнең тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә;

- Пиротехник эшләнмәләрне сату һәм куллану вакытында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарының тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә;

-Урамда куелган чыршылары бизәгәндә сертификацияләнгән электр гирляндалары кулланырга.

2. Кышкы чорда янгын гидрантларын, торак пунктларга, объектларга, торак йортларга илтүче юлларны һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларын кардан һәм боздан үз вакытында чистарту эшләрен оештырырга.

3. Янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

4. Янгын куркынычсызлыгы өчен учреждениеләр җитәкчеләренә, КФХ башлыкларына һәм торак йортларның милекчеләренә җаваплылык йөкләргә.

5. Бәйрәм көннәре һәм ял көннәрендә ДНД командирына график буенча патрульлек итүне оештырырга .

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.И.Әһлиева